ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МЭЛБАГЫШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтяниклар ур., 30 нче йорт, Мэлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 2019 елның 12 ноябре көнне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 12 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Мәлбагыш авылы, Җәлил ур. , 4 йорт, Мәлбагыш авыл мәдәният йорты залы ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш выл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 6 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Түбән Якый торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Түбән Якый торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Якый авылының 1 Май урамына юлларга таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш төяү)

- Түбән Якый авылында юлларны кардан чистарту;

- Түбән Якый авылында җәйге вакытта үлән чаптыру, территорияне җыештыру хезмәтләре;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү Көне " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Мәлбагыш авылында Нефтьчеләр урамы 30 йорт (Башкарма комитетның административ бинасы) ; Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 2 йорт (авыл мәдәният йорты; Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 йорт ( ФАП ); Каменка авылында Җәлил урамы, 1 йорт мәгълъмат стендларында

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: И.Ә.Әхтәмова